СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
20.08.2015

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
№341

Зеленодольск муниципаль районының аерым муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында Зеленодольск муниципаль районы Советы инициативасын хуплау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә халык фикерен белдереп, Зеленодольск муниципаль районы Советының инициативасын карап, Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының инициативасын хупларга һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрен карта-схема нигезендә үзгәртүгә ризалык бирергә (әлеге механизм карарга 1 нче кушымта).
2. «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чикләре тасвирламасын Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләр чикләре картасы нигезендә (әлеге карарга 2 нче кушымта) килештерергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**